ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СРЕДНЕКИРМЕНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ленина, д.16А, с. Средние Кирмени,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422171

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ УРТА КИРМӘН
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Ленин ур., 16А нчы йорт, Урта Кирмән авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422171

тел.(факс): (85563) 2-92-38;2-92-44 e-mail: Skimer.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Постановление
№ 24

Карар
28 июль 2025 ел

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Урта Кирмән авыл җирлеге Башкарма
комитетының 02.03.2023 елның 13
санлы карарына үзгәрешләр кертү
турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 28.12.2020 ел, № 2314 санлы «Гражданнар гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китерергә мөмкин булмаган яктырткыч җайланмалар, электр лампалары өлешендә җитештерү һәм куллану калдыкларын тиешенчә җыю, туплау, файдалану, зарарсызландыру, транспортировкалау һәм урнаштыру кагыйдәләрен раслау турындагы” (2024 нче елның 14 мартында керткән үзгәрешләр белән) карарына нигезләнеп, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы "Урта Кирмән авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампаларны туплау урынын (урынын) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында мәгълүмат бирү турында» 02.03.2023 ел, № 13 карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. Карарның 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Урта Кирмән авыл җирлеге территориясендә эшкәртелгән терекөмешле лампалар туплану урыннарының урнашуы турында әйләнә-тирә мохит торышының федераль дәүләт мәгълүмат системасында мондый урыннарның урнашуы

турында мәгълүмат урнаштыру юлы белән, шулай ук мәгълүматны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Урта Кирмән авыл җирлеге җирле үзидарә органнары биналарындагы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән кулланучыларга хәбәр итәргә ».

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), шулай ук Мамадыш муниципаль районының "Интернет"мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Урта Кирмән авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенә йөкләргә.

Җитәкче Б.Ф.Хасанов